КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 апрель г.Казань № 529

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән расланган Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга,

мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибенә, 4 пункттагы ундүртенче абзацындагы «Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына (иминиятләнгән туплана торган өлеш), Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бюджетына» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бюджетына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин